БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
30 апрель 2025 ел

**КАРАР**
№ 322

**Татарстан Республикасы Балтач район
Советының закон чыгару инициативасы турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясының 1 өлеше, «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 2005 елның 07 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13, 19 статьяларына тәңгәлләштереп, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Ямбурово поселогын бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Ямбурово поселогын бетерү һәм «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территория чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы проектын кертергә.

3. Күрсәтелгән закон проекты Татарстан Республикасы Дәүләт Советында каралган вакытта Татарстан Республикасы Балтач район Советы вәкиле итеп Балтач муниципаль район башлыгы урынбасары Наил Нургаязович Сабирҗановны билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль район лашлыгы урынбасарына йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе — Р.Р.Нотфуллин